**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 13 2018 елның "24" апреленнән

«Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турындагы 2014 елның 25 ноябрендәге №43 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (02.11.2015 №11 карары редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турындагы 2014 елның 25 декабрендәге 43 номерлы карарына (2015 елның 02 декабрендәге 11 номерлы карар редакциясендә), түбәндәге эчтәлекле бишенче - алтынчы абзацлар өстәп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- җирле салымнар буенча, суд пристав-башкаручы тарафыннан башкаручы производствоны тәмамлау турында карар чыгарылган очракта, «башкаручы производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләр буенча башкаручы документны түләтүчегә кайтару турында;
- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча, реструктуризация режимында һәм бөлгенлек (банкротлык) процедураларында булган салым түләүчеләргә бурычлардан тыш. "

2. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның түбәндәге веб-адрес буенча рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://aznakayevo. tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева